# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Элемтә турында

Әлеге Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасында башкарылучы элемтә өлкәсендәге эшчәнлекнең хокукый нигезен урнаштыра, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең республика һәм җирле органнарының шушы эшчәнлекне җайга салу буенча вәкаләтләрен, шулай ук элемтә өлкәсе эшчәнлегендә катнашучы яисә элемтә хезмәте күрсәтүләреннән файдаланучы физик һәм юридик затларның хокукларын һәм бурычларын билгели.

Әлеге Закон Татарстан Республикасы гражданнарының мәгълүмат тапшыру, алу һәм тарату хокукларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Элемтәнең билгеләнеше

Элемтә - Татарстан Республикасының җитештерү һәм социаль инфраструктурасының аерылгысыз өлеше һәм ул аның территориясендә, дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның Татарстан Республикасында электр һәм почта элемтәсе хезмәт күрсәтүләренә булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән үзара бәйләнешле җитештерү-хуҗалык комплексы буларак хезмәт итә.

Татарстан Республикасы элемтәсенә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан электр һәм почта элемтәсенең барлык челтәрләре һәм корылмалары керә, моңа законнар яисә махсус ки-

лешүләр нигезендә федераль элемтәгә кертелгән эчке җитештерү-технологик элемтә челтәрләре һәм элемтә объектлары керми.

Элемтә чаралары, исәпләү техникасы чаралары белән берлектә, мәгълүмат җыю, эшкәртү, туплау һәм тарату процессын тәэмин итүнең техник нигезен тәшкил итәләр.

Элемтәнең тотрыклы һәм сыйфатлы эшен үстерү һәм тәэмин итү җәмгыять үсешенең һәм дәүләт эшчәнлегенең мөһим шартлары булып тора.

2 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп терминнар

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп терминнар кулланыла:

электр элемтәсе - үткәргеч буйлап, радио-, оптик һәм башка электромагнит системалары аша тамгалар, сигналлар, язмача текст, сурәтләр, тавышлар тапшыру яисә кабул итү;

почта элемтәсе - почта юлламаларын, шулай ук акча күчерүләрне кабул итү, эшкәртү, ташу һәм илтеп җиткерү;

электр элемтәсе челтәрләре - белешмәләрне һәм башка төр документаль хәбәрләрне бер һәм берничә төр: телефон, телеграф, факсимиль (моңа электрон-исәпләү машиналары арасында мәгълүмат алмашу, телевизион, тавыш, радиотапшырулар һәм үткәргечләрнең башка төрләре дә керә) тапшыруны тәэмин итүче технологик системалар;

Татарстан Республикасы элемтәсенең үзара бәйләнешле челтәре - Татарстан Республикасы территориясендә электр элемтәсенең гомуми үзәкләштерелгән идарә белән тәэмин ителгән үзара технологик бәйләнешле челтәрләре комплексы;

гомуми кулланыш элемтә челтәре - барлык физик һәм юридик затлар куллану өчен ачык булган Татарстан Республикасы элемтәсенең үзара бәйләнешле челтәренең состав өлеше ул, әлеге затларга аның хезмәтләрен күрсәтүдән баш тарту рөхсәт ителми;

ведомство элемтә челтәрләре - дәүләт идарәсе органнарының җитештерү ихтыяҗларын һәм махсус ихтыяҗларны канәгатьләндерү өчен төзелүче һәм гомуми кулланыш элемтә челтәренә чыга торган электр элемтәсе челтәрләре;

эчке җитештерү һәм технологик элемтә челтәрләре - Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органнарының, шулай ук предп-

риятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның эчке җитештерү эшчәнлегенә һәм технологик процессларга идарә итү өчен төзелгән һәм гомуми кулланыш элемтәсе челтәренә чыкмый торган электр элемтәсе челтәрләре;

аерымланган элемтә челтәрләре - физик һәм юридик затларның гомуми кулланыш элемтә челтәренә чыкмый торган электр элемтәсе челтәрләре;

почта элемтәсе челтәре - почта элемтәсе объектларының һәм почта маршрутларының бергәлеге;

элемтә предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары, (алга таба - элемтә предприятиеләре) - милек рәвешләренә карамастан, физик һәм юридик затларга, эшчәнлекләренең төп төре буларак, электр һәм почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтүче юридик затлар;

дәүләт элемтә предприятиеләре - Татарстан Республикасының дәүләт милке объектларына кертелүче элемтә предприятиеләре, шул исәптән унитар элемтә предприятиеләре, махсуслаштырылган һәм территориаль аерымланган структур бүлекчәләр, филиаллар, иярчен предприятиеләр;

элемтә операторы - электр һәм почта элемтәсе хезмәтләре күрсәтергә хокукы булган физик яисә юридик зат;

элемтә хезмәте күрсәтү - электр элемтәсе челтәрләре аша хәбәрләр яисә почта юлламалары кабул итү, эшкәртү, тапшыру һәм илтеп җиткерү эшчәнлеге продукты;

элемтәдән файдаланучылар - элемтә хезмәте күрсәтүләреннән файдаланучы физик һәм юридик затлар;

лицензия - юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга элемтә өлкәсендә эшчәнлек алып барырга хокук бирүче махсус рөхсәт;

сертификат - тиешле рәвештә идентификацияләнгән җайланманың яисә элемтә хезмәте күрсәтүнең норматив документларга туры килүен раслаучы документ;

соңгы ноктадагы җайланма - абонент линияләренә тоташтырылучы һәм элемтә каналлары буйлап абонентлар биргән мәгълүматны тапшыру яисә кабул итү өчен электр элемтәсе чараларын оештыруның абонентлар кулланышында булган техник чаралары;

элемтә чаралары - электр элемтәсе хәбәрләрен оештыру, эшкәртү, тапшыру яисә кабул итү процессларын тәэмин итү өчен,

почта элемтәсе хезмәтен күрсәтү өчен кулланылучы техник чаралар;

почта юлламалары - хатлар һәм почта карточкалары, тиешенчә төрелгән бандерольләр, пакетлар, посылкалар, почта контейнерлары, матбугат басмалары;

почта элемтәсе объекты - почта элемтәсенең аерымланган бүлекчәләре (почтамтлар, тимер юл каршындагы почтамтлар, тимер юл станцияләре һәм аэропортлар каршындагы почта ташу бүлекләре, почта алмашу пунктлары, почта элемтәсе төеннәре, почта элемтәсе бүлекләре, почта элемтәсе пунктлары һәм башкалар);

почта әрҗәсе - хатлар һәм почта карточкалары җыю өчен билгеләнгән мәгълүм бер рәвештәге һәм күләмдәге әрҗә;

абонент почта шкафы - торак йортларда, шулай ук адресатлар почта юлламаларын алсын өчен авыл җирләренең почта китереп җиткерү участокларында куела торган әрҗәләре булган махсус шкаф;

терәк пунктының почта шкафы - почтаны китереп җиткерү участогында почта юлламаларын вакытлыча саклау өчен яисә адресат почта юлламаларын алсын өчен билгеләнгән махсус шкаф;

элемтәнең яшеренлеге - хат язышуның, телефон аша сөйләшүләрнең, почта, телеграф һәм башка төрдәге хәбәрләрнең яшеренлеген саклау.

3 статья. Әлеге Законның гамәлдә булу өлкәсе

Әлеге Закон элемтә өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр башкару эшчәнлегенә бәйле мөнәсәбәтләргә кагыла, аларны башкарганда дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, элемтә операторлары, кайбер урындагы затлар, шулай ук элемтәдән файдаланучылар катнаша.

4 статья. Элемтә өлкәсен гомуми җайга салу

Элемтә челтәрләре белән идарә итүне, оештыру-техник тәэминатны, элемтә челтәрләренең тотрыклы эшчәнлеген, шулай ук элемтә чараларын техник эксплуатацияләүне тәэмин итү мәсьәләләре буенча дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге органнары тарафыннан чыгарылучы норматив хокукый актлары һәм күрсәтмәләре,

кайда урнашуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, элемтә хезмәтләре күрсәтүче яисә алардан файдаланучы барлык физик һәм юридик затлар өчен дә мәҗбүри була.

Татарстан Республикасында элемтәне гомуми җайга салу өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендә вәкаләтле органы җаваплы була.

5 статья. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлек принциплары

Элемтә өлкәсендәге эшчәнлек түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- законлылык;
- базар мөнәсәбәтләренә нигезләнеп хуҗалык итү;
- элемтәнең социаль әһәмияткә ия төрләрен икътисадый һәм социаль үстерү программаларын, салым, кредит, инвестиция, лицензия һәм тариф сәясәтен әзерләү юлы белән дәүләт тарафыннан җайга салу;
- элемтә өлкәсендәге эшчәнлектә катнашуда һәм аның нәтиҗәләреннән файдалануда физик һәм юридик затларның тигез хокуклы булулары;
- Татарстан Республикасының бөтен территориясендә хәбәрләрне электр элемтәсе челтәрләре һәм чаралары аша тапшыру иреге, почта юлламалары һәм почта транзиты иреге;
- элемтәдән файдаланучыларның мәнфәгатьләрен үтәү;
- элемтә челтәрендә һәм чараларында төрле милек рәвешләре булу шартларында эшкуарлык эшчәнлеген үстерү һәм монополистик эшчәнлекне чикләү;
- Электр элемтәсенең халыкара берлеге һәм Почта элемтәсенең бөтендөнья уставы тәкъдимнәренә туры китереп, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территорияләрендәге бердәм стандартлар нигезендә элемтәнең челтәр технологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, элемтәнең ышанычлылыгын һәм идарә ителешен тәэмин итү;
- элемтә өлкәсендә дөньякүләм казанышларны гамәлгә кертү, чит илләрнең матди һәм финанс ресурсларын, алдынгы чит ил техникасын һәм идарә итү тәҗрибәсен җәлеп итү һәм куллану;
- элемтә өлкәсендә халыкара хезмәттәшлекне һәм бөтендөнья элемтәсен үстерүне киңәйтүгә ярдәм итү;

- дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге органнары алдында, милекчелекнең оештыру-хокукый рәвешләренә карамастан, элемтә предприятиеләренең хисап тотулары һәм шушы органнарның аларны тикшереп торулары.

Гадәттән тыш хәл шартларында әлеге статьяның беренче өлешендәге бишенче, алтынчы абзацларының гамәлдә булуы законда каралган очракларда һәм тәртиптә чикләнергә мөмкин.

## П бүлек. Элемтә челтәрләре

6 статья. Татарстан Республикасының үзара бәйләнешле элемтә челтәре

Татарстан Республикасының үзара бәйләнешле элемтә челтәре Татарстан Республикасы территориясендәге гомуми кулланыш элемтәнең үзара технологик бәйләнгән челтәрләренең һәм ведомство электр элемтәсе челтәрләренең комплексыннан гыйбарәт, ул, нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, гомуми үзәкләштерелгән идарә белән тәэмин ителә.

Үзара бәйләнешле элемтә челтәрен үстерү һәм камилләштерү, барлык челтәрләрнең һәм электр элемтәсе чараларының технологик бердәмлеген исәпкә алып, аларны комплекслы файдалану, аларның нәтиҗәлелеген һәм тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы, элемтәне үстерү программаларын гамәлгә ашырганда, үзара бәйләнешле элемтә челтәренең ышанычлылыгын арттыру чараларын үтәгәндә һәм, шушы челтәргә керүче элемтәнең барлык төр челтәрләре үсешен тәэмин иткән килеш, элемтә җиһазларының һәм материалларының мобилизацион резервын булдыргада, элемтә предприятиеләренә ярдәм итә.

7 статья. Гомуми кулланыш элемтә челтәре

Гомуми кулланыш элемтә челтәре, Татарстан Республикасының үзара бәйләнешле элемтә челтәренең бер өлеше буларак, барлык физик һәм юридик затларга элемтә хезмәте күрсәтү өчен оештырыла һәм аңа, аерымланган һәм ведомство элемтә челтәрләреннән гайре, кемгә буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан,

барлык электр элемтәсе челтәрләре керә. Гомуми кулланыш элемтә челтәрләренең эшләве һәм үсеше өчен җаваплылык элемтә өлкәсендәге дәүләт идарәсе органына йөкләтелә.

Гомуми кулланыш элемтә челтәрен төзегәндә һәм җиһазланганда, аңа тотрыксызландыру факторлары тәэсир итү очракларын күз алдында тотып, аның ышанычлылыгын тәэмин итү таләпләре исәпкә алына.

8 статья. Ведомство элемтә челтәрләре, физик һәм юридик затларның аерымланган элемтә челтәрләре

Ведомство элемтә челтәрләре Татарстан Республикасының дәүләт идарәсе республика органнарының җитештерү һәм махсус ихтыяҗларын тәэмин итү өчен төзелә һәм эшли, алар карамагында була һәм алар тарафыннан файдаланыла. Ведомство элемтә челтәрләре шулай ук халыкка һәм элемтәдән башка файдаланучыларга элемтә хезмәте күрсәтү өчен дә кулланылырга мөмкин. Ведомство элемтә челтәрләренең гомуми кулланыш элемтә челтәрләре белән кушылуы, ведомство элемтә челтәрләре техник чараларының һәм корылмаларының гомуми кулланыш элемтә челтәрләре өчен билгеләнгән таләпләргә һәм техник нормаларга туры килүен тәэмин иткән һәм әлеге Законның 15 статьясы нигезендә лицензия алынган тәкъдирдә генә, шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә аерымланган элемтә челтәрләре теләсә нинди физик һәм юридик зат тарафыннан, шул исәптән чит ил инвесторлары тарафыннан төзелергә мөмкин. Аерымланган элемтә челтәрләре операторлары тарафыннан элемтә хезмәтләре күрсәтү эшчәнлегенә әлеге Законның 15 статьясы нигезендә лицензияләү турындагы таләп кагыла.

Аерымланган элемтә челтәрләрен гомуми кулланыш элемтә челтәрләре белән кушканда әлеге челтәрләр гомуми кулланыш элемтә челтәре категориясенә күчәләр.

Ведомство һәм аерымланган элемтә челтәрләрен гомуми кулланыш элемтә челтәрләре белән кушу тәртибе законнар белән билгеләнә.

9 статья. Татарстан Республикасында идарә һәм хокук тәртибен саклау ихтыяҗлары өчен элемтә челтәрләре

Хөкүмәт элемтәсе шуңа махсус вәкаләтле органнар тарафыннан тәэмин ителә. Әлеге органнар, үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт серләренең сакланышын гамәлгә ашырып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарын элемтәнең махсус төрләре белән тәэмин итәләр. Мондый элемтә органнарының хокуклары һәм вазыйфалары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнә.

Гомуми кулланыш элемтә челтәре һәм ведомство элемтә челтәрләре каналлары законнарда каралган тәртиптә идарә итү һәм хокук тәртибен саклау ихтыяҗлары өчен арендага тапшырыла.

Идарә итү һәм хокук тәртибен саклау ихтыяҗлары өчен гомуми кулланыш элемтә челтәрен әзерләү һәм куллану тәртибе законнарда билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге органы, элемтә операторлары, милек рәвешләренә карамастан, элемтә каналларын идарә итү һәм хокук тәртибен саклау ихтыяҗлары өчен беренче чиратта биреп торуны тәэмин итәргә һәм элемтә каналларын алмаштыру яисә ватылган очракта аларны торгызу буенча беренчел кичектергесез чаралар күрергә тиеш.

10 статья. Почта элемтәсе

Татарстан Республикасы юрисдикциясендә булган почта элемтәсе универсаль элемтә хезмәте күрсәтүләрне тәэмин итүче учреждениеләрнең һәм транспорт чараларының бердәм технологик челтәреннән гыйбарәт.

Почта элемтәсе оешмалары посылкаларны, почта котейнерларын кабул итүне, эшкәртүне, ташуны һәм өләшүне, шулай ук шартнамә нигезендә матбугат басмаларын таратуны, пенсияләр, пособиеләр һәм башка максатчыл түләүләрне илтеп җиткерүне һәм түләүне тәэмин итәләр, телефон аша сөйләшүләрне һәм телеграф хәбәрләрен кабул итү һәм тапшыру хезмәтләрен үтиләр, кыйммәтле кәгазьләр сатуны, акчалата керемнәрне кабул итүне һәм инкассацияне, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне кабул итүне гамәлгә ашыралар һәм законнарда рөхсәт ителгән башка эшчәнлекне башка-

ралар.

Татарстан Республикасының барлык территориясендә почта юлламалары һәм почта транзиты иреге гарантияләнә.

Почта элемтәсе хезмәтләре билгеләнгән тәртиптә бирелә торган лицензияләр нигезендә почта элемтәсенең дәүләткә карамаган предприятиеләре тарафыннан да күрсәтелергә мөмкин.

Татарстан Республикасының дәүләти һәм дәүләткә карамаган почта элемтәсе оешмалары почта юлламаларын алмашу өчен бердәм почта территориясе төзиләр.

Почта элемтәсе үсешенә һәм эшчәнлегенә дәүләт икътисадый ярдәм күрсәтә, аның хезмәткәрләрен социаль яклый.

### Ш бүлек. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлеккә идарә итү

**11 статья.** Элемтә өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт идарәсе органы

Татарстан Республикасында элемтә өлкәсендәге эшчәнлеккә идарә итү дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендә шуңа вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла, ул үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы элемтәсенең барлык төрләренең торышы һәм үсеше өчен җаваплы була.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә органы вәкаләтле органы вәкаләтләре һәм аның эшчәнлеген оештыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан расланучы нигезләмәдә билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендә вәкаләтле органы ведомствоара килешүләр нигезендә башкарма хакимиятнең элемтә өлкәсендәге тиешле федераль органнары тарафыннан тапшырыла торган вәкаләтләрне дә башкара.

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органының төп бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- элемтә өлкәсендә дәүләт сәясәте буенча тәкъдимнәрне әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү, элемтә өлкәсен гомуми җайга салу;
- элемтәне үстерү проектларын әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

- электр һәм почта элемтәсе эшчәнлеген һәм үсешен тармакара җайга салу;
- элемтә өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген һәм тикшереп торуын оештыру һәм тәэмин итү;
- элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне лицензияләү;
- республикада элемтә өлкәсендәге тариф сәясәтен уздыру һәм элемтә хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан җайга салынучы тарифларны үзгәртү буенча тәкъдимнәр әзерләү.

12 статья. Радиоешлык спектрын куллануны җайга салу

Радиоешлыклардан Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле файдалану максатларында радиоешлык спектрын законнар һәм ведомствоара килешүләр нигезендә билгеләнүче радиоешлык ресурсы чикләрендә тарату Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла.

Радиоешлыкларны бүлү, элемтә чараларын, шул исәптән теле,-радиотапшырулар өчен кулланылучы һәм электромагнит нурланыш чыганаклары булган элемтә чараларын теркәү тәртибе, радиоэлектрон чараларны һәм югары ешлыктагы җайланмаларны әзерләү, проектлау, төзү, сатып алу, куллану һәм чит илләрдән кертү өчен аерым шартлар законнарда билгеләнә.

Элемтә предприятиеләренең ешлык үзләштерүләре дәүләт идарәсен һәм хокук тәртибен саклауны тәэмин итү мәнфәгатьләрендә, башка ешлыкларга күчү белән бәйле зыянны элемтә предприятиеләренә компенсацияләп, үзгәртелергә дә мөмкин.

13 статья. Гадәттән тыш хәлләрдә һәм гадәттән тыш хәл шартларында элемтә челтәрләренә идарә итү

Гадәттән тыш хәлләрдә элемтә челтәрләренә идарә итү законнар нигезендә, Хөкүмәт элемтәсенә идарә итү органы, дәүләт идарәсенең гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча вәкаләтле органы һәм үз карамакларында ведомство элемтә челтәрләре булган дәүләт идарәсенең башка органнары белән берлектә, дәүләт идарәсенең элемтә әлкәсендәге вәкаләтле органы

тарафыннан башкарыла.

Табигый бәла-казалар, карантиннар һәм законнарда каралган башка гадәттән тыш хәлләр вакытында шуңа вәкаләтле дәүләт органнары, нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, теләсә кайсы элемтә челтәреннән һәм чараларыннан өстенлекле файдалану, шулай ук аларның эшчәнлеген туктатып тору хокукына ия.

Гадәттән тыш хәл урнаштыру белән бәйле вакыйгаларны бетерү эшләрен җайга салу өчен гадәттән тыш хәл турындагы законнар нигезендә вакытлы махсус элемтә органнары төзелергә мөмкин, аларга Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендә вәкаләтле органының вәкаләтләре тулысынча яисә өлешчә тапшырыла.

Әлеге статьяның икенче өлешендә саналган очракларда элемтә челтәрләреннән һәм чараларыннан файдаланганда дәүләткә карамаган элемтә предприятиеләренә китерелгән зыян тиешле бюджетларның акчалары исәбеннән түләнә.

<u>14 статья.</u> Оператив эзләү эшчәнлеген башкаручы органнар белән элемтә предприятиеләренең үзара хезмәттәшлеге

Нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче элемтә предприятиеләре, элемтә операторлары элемтә челтәрләрен әзерләгәндә, оештырганда һәм кулланганда оператив эзләү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче органнарга ярдәм итәргә һәм оператив эзләү гамәлләрен законнар нигезендә элемтә челтәрләре аша үздыру мөмкинлеге тудырырга, әлеге гамәлләрне башкаруның оештыру һәм тактик алымнарын ачмаслык чаралар күрергә тиеш.

Элемтә чараларын шәхес, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләренә зыян китерерлек җинаятьчел максатларда куллану очракларында, махсус вәкаләтле дәүләт органнары, нинди ведомствога буйсынуларына һәм милек рәвешләренә карамастан, теләсә кайсы элемтә челтәренең һәм чарасының эшчәнлеген туктатып торырга хокуклы.

15 статья. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне лицензияләү

Элемтә хезмәте күрсәтү, элемтә корылмаларын һәм чараларын проектлаштыру, төзү һәм техник эксплуатацияләү белән шөгыльләнүче физик һәм юридик затларның эшчәнлеге шушы максатлар өчен тиешенчә алынган һәм рәсмиләштерелгән лицензия буенча башкарыла. Лицензия бирү шартлары һәм тәртибе, лицензияләүнең башка мәсьәләләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган норматив-хокукый актлар белән билгеләнә.

Теле-, радиотапшырулар өчен элемтә өлкәсендәге эшчәнлеккә лицензияләр бирү, шулай ук теле-,радиотапшырулар өчен кулланылучы һәм куллануга планлаштырылучы ешлыклар исемлегенә кертелгән ешлыкларны үзләштерү теле,-радиотапшырулар өчен билгеләнгән элемтә чараларына ия булучы, алардан файдаланучы һәм алар белән эш итүче яисә теле,-радиотапшырулар максатларында кулланылучы элемтә чараларына ия булу, алардан файдалану һәм алар белән эш итү хокукын алырга ниятләүче физик һәм юридик затларның гаризалары буенча гамәлгә ашырыла.

Лицензия түбәндәге очракларда таләп ителми, әгәр элемтә челтәре:

җитештерүнең эчке яисә технологик максатларында файдаланылырга тиешле булса;

бары тик Татарстан Республикасында идарә итү һәм хокук тәртибен саклау ихтыяҗлары өчен генә, шулай ук законнарда каралган башка очракларда гына файдаланылса;

бер үк бинада яисә үзара бер-берсенә кушылган берничә бинада урнашкан булса йә автотранспорт чарасына, судного, самолетка яисә транспортның башка төренә урнаштырылган булса.

Элемтә өлкәсендә лицензиясез яисә аннан файдалану тәртибен бозып эшчәнлек алып баручы физик һәм юридик затлар законнарда билгеләнгәнчә җаваплы булалар.

Дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органының элемтә эшчәнлеген лицензияләү буенча хокукка каршы гамәлләренә карата судка яисә арбитраж судка шикаять белдерелергә мөмкин.

16 статья. Элемтә чараларын сертификацияләү

Татарстан Республикасының үзара бәйләнешле элемтә челтә-

рендә файдаланылучы барлык элемтә чаралары билгеләнгән стандартларга, башка нормаларга һәм техник таләпләргә туры килү-килмәү буенча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан мәҗбүри тикшерү (сертификация) үзарга тиеш.

Гомуми кулланыш элемтә челтәре күрсәтә торган элемтә хезмәтләре дә сертификацияләнергә мөмкин.

Сертификация уздыру тәртибе законнар белән билгеләнә.

Элемтә чараларын сертификацияләү кагыйдәләрен бозуда гаеплеләр законнарда билгеләнгәнчә җаваплы булалар.

## IV бүлек. Элемтә өлкәсендә икътисадый эшчәнлек нигезләре

17 статья. Элемтә челтәрләренә һәм чараларына милекчелек

Татарстан Республикасы территориясендә элемтә предприятиеләре уртак икътисадый мәйданның бергәлеге, милек рәвешләренең күптөрлелеге нигезендә һәм конкуренция шартларында төзелә һәм эшли.

Татарстан Республикасында элемтә челтәрләре һәм чаралары хосусый һәм дәүләт (республика һәм коммуналь) милкендә, җирле үзидарә милкендә, иҗтимагый берләшмәләр милкендә булырга мөмкин. Татарстан Республикасында элемтә челтәрләре һәм чаралары чит дәүләтләр, халыкара оешмалар һәм чит ил юридик затлары, гражданнары, гражданлыксыз затлар милкендә булырга мөмкин.

18 статья. Элемтә челтәрләренең һәм чараларының милек рәвешен үзгәртү

Татарстан Республикасында элемтә челтәрләренең һәм чараларының милек рәвешләре Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда күрсәтелгән тәртиптә үзгәртелә.

Чит ил инвесторлары дәүләт һәм коммуналь элемтә предприятиеләрен хосусыйлаштыруда Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарда билгеләнгән шартларда катнаша алалар.

Элемтә челтәрләренең һәм чараларының милек рәвешләре

элемтә челтәрләре эшчәнлегенең технологик режимы, шулай ук физик һәм юридик затларның элемтә хезмәтеннән файдалану хокукы бозылмаса гына үзгәртелә.

Почта элемтәсенең дәүләт предприятиеләре һәм учреждениеләре мөлкәте (моңа почта элемтәсе челтәрләре һәм чаралары да керә) хосусыйлаштырылмый.

19 статья. Элемтә үсешен инвестицияләү һәм аның эшчәнлеген финанслау

Элемтә үсешен инвестицияләү инвестиция эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Элемтә үсешенә Татарстан Республикасының Республика бюджеты исәбеннән дәүләт инвестицияләре кертү турындагы карарлар Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә элемтә үсеше буенча дәүләт программалары нигезендә кабул ителәләр. Элемтә үсешенең дәүләт программалары дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан әзерләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Элемтә үсеше программаларын һәм элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне Татарстан Республикасының Республика бюджеты акчалары исәбеннән финанслау Республика бюджетында Татарстан Республикасының тиешле елга республика инвестиция программасында аерым юл рәвешендә күрсәтелә.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары тиешле территорияләрнең социаль-икътисадый үсеше планнары һәм элемтә үсешенең дәүләт программалары нигезендә үз территорияләрендәге элемтә үсеше юнәлешләрен билгели һәм аңа кертелүче инвестицияләрне куллану программаларын әзерли, бу программалар исә тиешле бюджетларның акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Элемтә эшчәнлеген үстерү һәм тәэмин итү проектларын тормышка ашыруда катнашучы физик һәм юридик затларга, шул исәптән чит ил инвесторларына билгеләнгән тәртиптә законнарда каралган гарантияләр, өстенлекле ташламалы кредитлар, салым буенча һәм башка өстенлекле ташламалар бирелә.

20 статья. Элемтә өлкәсендә конкуренция

Дәүләт идарәсенең элемтә өлкәсендәге вәкаләтле органы, гайре монополия сәясәте уздырып һәм яңа икътисадый структураларга ярдәм күрсәтеп, лицензияләү шартларының норматив документлары таләпләре үтәлешен тикшереп тору юлы белән элемтә хезмәте күрсәткәндә, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдәге законнар нигезендә гадел конкуренцияне хупларга һәм аңа ярдәм итәргә тиеш.

Элемтә операторлары эш урыннарыннан үз мәнфәгатьләрендә файдаланган яисә конкуренциягә тоткарлык ясый йә аны чикли торган башка гамәлләр кылган өчен законнарда билгеләнгәнчә җаваплы булалар.

21 статья. Элемтә хезмәте күрсәтү тарифлары

Элемтә хезмәте күрсәтү тарифлары шартнамә нигезендә билгеләнә.

Законнарда каралган очракларда элемтә хезмәте күрсәтүләрнең аерым төрләре буенча тарифлар элемтә өлкәсендә табигый монополияләрнең вәкаләтле федераль хезмәте аша дәүләт тарафыннан, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты һәм Татарстан Республикасының элемтә өлкәсендәге дәүләт идарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Кичектергесез ашыгыч хезмәтләрне (янгыннан саклау, милиция, ашыгыч медицина ярдәме, газга бәйләнешле бәла-казаларга каршы хезмәт күрсәтү, тауларда коткару хезмәте һ.б.) чакыру барлык физик һәм юридик затлар тарафыннан бушлай гамәлгә ашырыла.

Челтәрара тоташулар өчен түләү тиешле элемтә предприятиеләре арасында килешенгән шартнамәләр, шартлар һәм нигезләмәләр нигезендә билгеләнә.

Әлеге мәсьәләләр буенча бәхәсләр судта яисә арбитраж судта карала.

## V бүлек. Элемтә предприятиеләренең, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм предприятиеләрнең үзара мөнәсәбәтләре

### 22 статья. Элемтә объектларын урнаштыру

Шәһәрләрне һәм башка торак пунктларын, торак районнарын һәм комплексларын, аерым биналарны һәм корылмаларны проектлаштырганда һәм үстергәндә, архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары, проектлау оешмалары элемтә предприятиеләрен урнаштыру өчен нормативлар нигезендә биналар төзүне күздә тотарга тиеш.

Аерым биналарны һәм корылмаларны проектлаштырганда һәм төзегәндә, кирәк булса, элемтә чараларын урнаштыру өчен нормативлар нигезендә махсус бүлмәләр ясау күздә тотыла.

Дәүләт идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары гамәлдәге (яисә төзелә торган) торак биналарыннан йә башка биналардан элемтә предприятиеләренә тиешле техник нормаларга туры килүче аерым бүлмәләр бирергә тиешләр.

Почта элемтәсе оешмалары автовокзалларда, тимер юл вокзалларында һәм станцияләрендә, аэропортларда, елга портларында һәм пристаньнәрендә технологик нормалар нигезендә почта элемтәсе объектларын урнаштыра алалар.

### 23 статья. Элемтә челтәрләрен үстерү эшләрен башкарганда җирләрдән, биналардан һәм корылмалардан файдалану

Элемтә хезмәте күрсәтү эшчәнлеге белән шөгыльләнүче физик һәм юридик затлар милкенә билгеләнгән тәртиптә бирелүче яисә милекчеләре тарафыннан даими яисә вакытлыча файдалануга, шул исәптән арендага, тапшырылучы җир кишәрлекләре элемтә җирләре булалар.

Җир кишәрлекләрен бирү, саклау зоналарын билгеләү һәм урман ызаннары ясау тәртибе, алардан файдалану режимы законнар белән билгеләнә.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затларның элемтә өлкәсендәге эшчәнлекләре туктатылганда, аларның җир ки-

шәрлегенә хокуклары җир турындагы законнарда билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә туктатыла.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән затларга бирелүче җир кишәрлекләренең, шул исәптән саклау зоналарының һәм урман ызаннарының үлчәмнәре шушы эшчәнлек төре өчен мәгълүм тәртиптә расланган җир бүлеп бирү нормалары һәм техник проектлау документлары нигезендә билгеләнә.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән физик һәм юридик затлар тиешле максатлар өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә билгеләнгән тәртиптә элемтә биналары һәм корылмалары төзи алалар, шулай ук ул җир кишәрлекләрендәге күчемсез мөлкәттән законнар нигезендә файдалана алалар. Күрсәтелгән затлар шулай ук бина түбәләрендә, багана терәкләрендә, күперләрдә, коллекторларда, метрополитен һәм тимер юл туннельләрендә, башка инженерлык объектларында элемтә корылмалары төзи алалар, шулай ук, шушы җир кишәрлекләренең, биналарның яисә корылмаларның милекчеләре, җир биләүчеләре, җирдән файдаланучылары, шул исәптән арендачылар белән килешеп, элемтә аппаратлары урнаштыра һәм аларны эшләтә алалар. Милекчеләр, җир биләүчеләр, җирдән файдаланучылар, шул исәптән арендачылар, бары тик Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, башка норматив-хокукый актларында каралган нигезләрдә генә, элемтә предпрятиеләренең күрсәтелгән эшләрне башкаруларына каршы була алалар. Бәхәс туганда мәсьәлә судта яисә арбитраж судта хәл ителергә мөмкин.

Торак пунктлары һәм аерым биналар, юллар һәм күперләр төзи башлауга, аларны киңәйтүгә һәм реконструкцияләүгә, яңа җирләр үзләштерүгә, мелиорация системасын үзгәртеп төзүгә, файдалы казылмалар эшкәртүгә бәйле рәвештә элемтә корылмаларын күчерү яисә үзгәртеп кору стандартлар нигезендә һәм элемтә челтәрләре һәм чаралары хуҗаларының яки алардан файдаланучыларның техник шартлары буенча төзелеш заказчысы тарафыннан үз исәбеннән башкарыла. Бу вакытта элемтә чараларының егәрлеген арттыру элемтә предприятиеләре исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Җир кишәрлегендә, бинада яисә корылмада эшләр тәгәлләнгәч, элемтә предприятиесе яки заказчы үз исәбеннән җир кишәрлеген, бинаны яисә корылманы баштагы халәтенә китерергә, йә милекчегә, җир биләүчегә, җирдән файдаланучыга яки арендачыга

176



китерелгән зыянны түләргә тиеш.

Проектлау эшләрен башкарганда җир кишәрлеге тартып алынган яисә чит җир кишәрлегеннән һәм башка күчемсез мөлкәттән файдалану хокукы чикләнгән (сервитут) очракта түләп алу бәясе, шулай ук җир кишәрлегеннән һәм башка күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен түләү законнарда күрсәтелгән тәртиптә билгеләнә.

Почта элемтәсе предприятиеләре тераk пунктының почта шкафларын һәм почта әрҗәләрен торак һәм административ биналарда һәм хатлар, почта карточкалары җыю өчен уңайлы башка корылмаларда урнаштырырга хокуклы.

Абонент почта шкафлары йортларның беренче катында төзелеш оешмалары тарафыннан куела. Абонент почта шкафларын сатып алу һәм урнаштыру чыгымнары бу йортларны төзү сметасына кертелә. Аларны төзек хәлдә тоту торак - эксплуатация оешмалары, йорт хуҗалары һәм милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

<u>24 статья.</u> Элемтә чараларын, корылмаларын, радиоешлык спектрын яклау һәм саклау

Элемтә чаралары, корылмалары һәм радиоешлык спектры дәүләт яклавында була.

Элемтә чараларын, корылмаларын һәм радиоешлык спектрын саклау тәртибе законнар белән билгеләнә.

Элемтә чараларына, корылмаларына зыян китергән, элемтә челтәрләренә һәм чараларына рөхсәтсез тоташтырылган, радиоэлектрон чараларны һәм югары ешлыклы җайланмаларны читтән кертүнең, куллануның һәм теркәүнең билгеләнгән тәртибен, барлык юнәлештәге радиоэлектрон чараларны һәм югары ешлыклы җайланмаларны эшләтү өчен ешлыклардан файдалану тәртибен бозган, шулай ук теле-һәм радио дулкыннарны тотуга нормадан тыш тоткарлык ясаган физик һәм юридик затлар законнарда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар, шулай ук зыянны бетерү өчен тотылган чыгымнарны һәм элемтә предприятиеләренең алынмаган табышын да түлиләр.

25 статья. Элемтә челтәрләрендәге бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү

Элемтә челтәрләрендәге бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү элемтә операторлары катнашында тиешле дәүләт хезмәтләре тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасының тиешле дәүләт идарәсе органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары элемтә челтәрләрендәге бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү буенча элемтә предприятиеләренә кичекмәстән ярдәм күрсәтәләр, кирәк булса, тиешле элемтә предприятиеләре исәбеннән түләп, хакимият органнары карары буенча - тиешле бюджет акчалары исәбеннән түләп, аларны эшче көчләр, транспорт һәм башка чаралар белән тәэмин итәләр.

Элемтә челтәрләрендәге бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү буенча эшләрне башкару өчен элемтә чаралары урнаштырылган җир кишәрлеге, бинасы яисә корылмасы милекчесенең (биләүчесенең, файдаланучысының, арендачының) ризалыгын алу таләп ителми. Милекчегә (биләүчегә, файдаланучыга, арендачыга) китерелгән зыян тиешле элемтә предприятиесе акчасыннан түләнергә тиеш. Зыянны түләгән элемтә предприятиесе зарар китерүче затка регресс таләпләр куярга хокуклы.

Элемтә челтәрләрендәге бәла-казаларның нәтиҗәләрен бетерү эшләренә бәла-казалардан зыян килгән элемтә чараларын торгызу һәм реконструкцияләү, шулай ук табигатьне саклау буенча тиешле гамәлләр башкару керә.

Элемтә челтәрләрендәге бәла-казалардан зыян күргән элемтә операторларына, башка физик һәм юридик затларга компенсация зыян китергән зат яисә иминләштерү фондлары исәбеннән түләнә.

Элемтә челтәрләрендәге бәла-казалар аркасында зыян күргән элемтә операторларына, башка физик һәм юридик затларга компенсация тиешле дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары карары буенча тиешле бюджет акчаларыннан да түләнергә мөмкин.

26 статья. Транспорт чараларыннан файдалану

Почта элемтәсе предприятиеләренә килешү шартларында тимер юл, елга, һава юлы һәм автомобиль транспортының барлык маршрутлары һәм линияләре буйлап почта элемтәсе хезмәткәрләре җи-

тәкчелегендә почта йөртергә яисә аны ташуны транспорт оешмалары җаваплылыгына тапшырырга хокук бирелә.

Бер транспорт предприятиесе дә даими халыкара һәм шәһәрара маршрут буенча үз транспорт чараларында почта йөртү өчен шартнамә төзүдән баш тарта алмый.

Зарарланган элемтә челтәрләрен һәм чараларын торгызу буенча кичектергесез техник эшләр башкарганда элемтә предприятиеләренә транспорт чаралары хуҗалары тарафыннан чиратсыз бирелә.

Элемтә предприятиеләренең транспорт чараларында махсус символика булырга мөмкин һәм элемтә предприятиеләренең рөхсәтеннән башка алар элемтә өлкәсендәге эшчәнлеккә кагылышы булмаган хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр башкару өчен файдаланылмый.

Элемтә предприятиеләренең, шулай ук башка предприятиеләрнең почта ташуда файдаланылучы транспорт чараларына паром белән аркылы чыгудан беренче чиратта бушлай файдалану хокукы бирелә.

## VI бүлек. Элемтәдән файдаланучыларның хокуклары

### 27 статья. Элемтәдән файдалану хокукы

Татарстан Республикасы территориясендә элемтәдән файдаланучыларның барысы да тигез шартларда электр һәм почта элемтәсе челтәрләре аша хәбәр тапшырырга хокуклы.

Татарстан Республикасы территориясендә элемтәдән файдаланучыларның берсенә дә гомуми кулланыш элемтә челтәрләреннән файдаланугa кертә куелмый.

Элемтәдән файдаланучылар һәм операторлар гомуми кулланылыштагы элемтә челтәренә үзләренең элемтә челтәрләрен һәм соңгы ноктадагы җайланмаларны тоташтырырга хокуклы, монда Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнгән тоташтыру шартлары үтәлергә тиеш, ә алар тиешле элемтә операторлары тарафыннан бирелә яисә лицензиядә күрсәтелә.

Элемтә челтәрләренә бары тик билгеләнгән тәртиптә сертификацияләнгән элемтә чаралары гына тоташтырыла.

179



28 статья. Элемтә хезмәте күрсәтүләрнең сыйфаты

Элемтә операторларының барысы да файдаланучыларга элемтә хезмәте күрсәтүнең сыйфатына, стандартларына, техник нормаларына, сертификатларына, шартнамә шартларына туры килә торган элемтә хезмәте күрсәтергә тиеш.

29 статья. Элемтәдән файдалануның өстенлеге

Элемтә челтәрләренең һәм чараларының хуҗалары суда, җирдә, һавада кеше гомеренең иминлегенә, сборона, иминлек һәм хокук тәртибен саклау өлкәсендә кичектергесез чаралар күрүгә кагылышлы барлык хәбәрләргә, шулай ук зур бәла-казалар, һәлакәтләр, эпидемияләр, эпизоотияләр һәм табигать бәла-казалары турындагы хәбәрләргә законнар нигезендә абсолют өстенлек бирергә тиешләр.

30 статья. Элемтәдән файдаланганда бирелүче ташламалар һәм өстенлекләр

Дәүләт органнарындагы урындагы затларның кайбер категорияләренә, чит дәүләтләрнең дипломатик һәм консуллык вәкилләренә, халыкара оешмаларның вәкилләренә, шулай ук гражданнарның аерым төркемнәренә электр һәм почта элемтәсеннән файдаланганда чиратны саклану, элемтә хезмәте күрсәтүдән файдалану тәртибе һәм элемтә хезмәте күрсәтелгән өчен түләү күләме буенча ташламалар һәм өстенлекләр билгеләнергә мөмкин.

Ташламалар исемлеге, шулай ук ташламаларга һәм өстенлекләргә хокукы булган урындагы затларның һәм гражданнарның категорияләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән, шулай ук Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре һәм килешүләре белән билгеләнә.

Элемтә хезмәте күрсәтелгән өчен түләү буенча Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар нигезендә ташламалар бирелгәндә элемтә предприятиесе тарафыннан алынмый калган керемнәр тиешле бюджет акчалары исәбеннән түләнә.

Әгәр ташламаларны дәүләт хакимиятенең җирле органнары

билгеләсә, элемтә предприятиеләре алмый калган табыш җирле бюджет исәбеннән түләнә.

Ташламалардан һәм дәүләт тарафыннан җайга салынучы тарифлардан файдалану аркасында дәүләт элемтә предприятиеләре алып җиткермәгән керемнәрне түләү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

31 статья. Элемтәдән файдаланучыларның хокукларын яклау

Элемтәдән файдаланучыларның электр һәм почта элемтәсе буенча тиешле дәрәҗәдә сыйфатлы хезмәт күрсәтелү, шундый хезмәт күрсәтүләр һәм аларны үтәүчеләр турында мәгълүмат алу хокукларын яклау, шулай ук бу хокукларны гамәлгә ашыру механизмы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

32 статья. Элемтәнең яшеренлеге

Барлык элемтә операторлары хат аша хәбәрләшүләрнең, телефон аша сөйләшүләрнең, электр элемтәсе челтәрләре буенча тапшырылучы һәм почта элемтәсе челтәрләре буенча җибәрелүче хәбәрләрнең Татарстан Республикасы Конституциясендә билгеләнгән яшеренлеген тәэмин итәргә тиеш.

Барлык элемтә операторлары элемтәнең яшеренлеген саклауны тәэмин итәргә тиеш.

Почта юлламалары һәм электр элемтәсе челтәрләре аша тапшырылучы хәбәрләр турында мәгълүмат, шулай ук бу юлламалар һәм хәбәрләр үзләре бары тик җибәрүчеләргә һәм адресатларга яисә аларның законлы вәкилләренә генә тапшырылырга мөмкин.

Телефон аша сөйләшүләрне тыңлау, электр элемтәсеннән алынган хәбәрләр белән танышу, почта юлламаларын һәм документаль корреспонденцияне тоткарлау, тикшерү һәм ачып алу, алар турында белешмәләр алу, шулай ук элемтә яшеренлеген башкача чикләү бары тик законда каралган очракларда гына рөхсәт ителә.

Күрсәтелгән нигезләмәләрне бозган урындагы һәм башка затлар, элемтә хезмәткәрләре законнарда билгеләнгән тәртиптә җавапка тартылалар.

181



33 статья. Почта юлламаларының һәм башка юлламаларның сакланышы

Элемтә операторлары почта юлламаларының һәм башка юлламаларның сакланышы, аларны тиешле урынга илтеп җиткерү өчен җаваплы булалар.

34 статья. Почта аша җибәрү тыелган әйберләр исемлеге

Почта аша җибәрү тыелган әйберләрнең исемлеге, аларны алу һәм юкка чыгару тәртибе норматив-хокукый актлар белән билгеләнә.

Почта элемтәсе предприятиеләре почта аша җибәрү тыелган юлламаларны алып калырга, шулай ук почта аша җибәрелүче юлламалар почта хезмәткәрләренең яисә өченче затларның сәламәтлегенә һәм гомеренә куркыныч тудырса һәм бу хәвефне башкача бетереп булмаса, ул юлламаларны юк итәргә яисә юкка чыгаруга рөхсәт бирергә хаклы.

35 статья. Кыйммәте игълан ителгән почта юлламалары

Почта юлламасы җибәрүче шул юлламаның хакы чикләрендә аның кыйммәтен билгеләргә хокуклы.

Кыйммәте игълан ителеп, почта аша җибәрелгән юллама югалган яисә аңа зыян килгән очракта элемтә оешмасы җибәрүчегә китерелгән зыянны законнар нигезендә түләргә тиеш.

## VII бүлек. Элемтә хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре

36 статья. Телләрне һәм алфавитларны элемтә предприятиеләре эшчәнлегендә куллану

Татарстан Республикасы чикләреннән читкә телеграммалар һәм почта юлламалары җибәрүченең һәм аларны алучының адреслары русча языла, ә республика чикләрендә телеграммалар һәм почта юлламалары җибәрүченең һәм аларны алучының адреслары Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә языла.

Телеграмма тексты рус яисә латин алфавиты хәрефләре белән

теләсә кайсы телдә язылырга мөмкин.

Электр һәм почта элемтәсе челтәрләре буенча тапшырылучы халыкара хәбәрләр халыкара шартнамәләр һәм килешүләр нигезләмәләрендә билгеләнгән телләрдә эшкәртелә.

## VIII бүлек. Элемтә өлкәсендә эшчәнлек алып баруның җаваплылыгы

37 статья. Элемтә өлкәсендә эшчәнлек алып баруның җаваплылыгы

Элемтә өлкәсендә эшчәнлек алып барганда әлеге Законны, башка норматив-хокукый актларны бозучы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук физик һәм юридик затлар законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

Кыйммәтле почта юлламаларын югалткан, аларга зыян китергән өчен, почта юлламаларының күрсәтелгән кыйммәткә туры килмәгәне, телеграмма текстының мәгънәсен үзгәртеп бозган өчен, телеграмманы түләнгән күләмдә адресатка китермәгән яисә аны биргән мизгелдән 24 сәгать вакыт үткәч кенә тапшырган өчен (электр элемтәсе булмаган торак пунктларына адресланган телеграммалардан гайре)элемтә операторлары мөлкәти җаваплы булалар.

Почта аша теркәлеп китә торган бүтән юлламаларны җибәрү яисә илтеп тапшыру буенча вазыйфаларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен почта элемтәсе оешмаларының җаваплылыгы законнар белән билгеләнә.

Әлеге Законның 29 статьясында каралган очраклардан гайре, элемтәдән файдаланучы электр элемтәсе челтәренең соңгы ноктадагы җиһазларыннан файдалану кагыйдәләрен бозганда, элемтә челтәрендә сертификацияләнмәгән җиһазлардан файдаланганда, электр хезмәте күрсәтүләре өчен вакытында түләмәгәндә, элемтә операторы җитешсезлекләр бетерелгәнчегә кадәр элемтәдән файдаланучының электр элемтәсеннән файдалануын туктатып торырга хокуклы, элемтәдән файдаланучы элемтә операторының алынмаган керемнәрен түли һәм элемтә операторына җиһазларны бозып йә эшләтмичә тотып китергән зыянны компенсацияли.

Почта һәм телеграф аша җибәрелүче нинди дә булса юллама дәүләт элемтә предприятиеләре хезмәткәрләре гаебе белән югал-

ганда йә китерү тоткарланганда почта юлламалары җитәрлек булмаганда йә аларга зыян килгәндә, алар үз предприятиеләре каршында матди җаваплы булалар, бу җаваплылык, әгәр тиешле законда башка төр җаваплылык чарасы каралмаган булса, кулланучы каршында элемтә предприятиесенең мөлкәти җаваплылыгы дәрәҗәсендә билгеләнә.

Әгәр хәбәрләрне тапшыру яисә кабул итү буенча, юлламаларны почта аша җибәрү яисә китереп бирү буенча йөкләмәләрнең элемтәдән файдаланучы гаебе белән йә хәл ителмәслек сәбәпләр аркасында үтәлмәве яки тиешенчә үтәлмәве расланса, элемтә операторы болар өчен җавап бирми.

38 статья. Претензияләр һәм дәгъвалар бирү тәртибе

Элемтә хөзмәте күрсәткәндә яисә элемтә өлкәсендә эшләр башкарганда үз вазыйфаларын үтәмәгән йә тиешенчә үтәмәгән хезмәт күрсәтүче яисә эшләүче элемтә операторына элемтәдән файдаланучы законнарда билгеләнгән тәртиптә претензия белдерә, шул исәптән зыянны түләүне таләп итә ала.

Претензияләр язмача бирелә һәм алар билгеләнгән тәртиптә теркәлергә тиеш.

39 статья. Зыянны түләү

Элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне башкарганда китерелгән зыян ихтыярый түләнә яисә законнарда билгеләнгән тәртиптә суд йә арбитраж суды карары буенча түләтелә.

## IX бүлек. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлек мәсьәләләре буенча бәхәсләрне хәл итү

40 статья. Элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне башкарганда килеп чыккан бәхәсләрне хәл итү

Элемтә өлкәсендәге эшчәнлекне башкарганда элемтә предприятиеләре арасында, шулай ук элемтәдән файдаланучылар белән элемтә предприятиеләре арасында килеп чыгучы бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Авыл хуҗалыгының уңдырышлы җирләрендә яисә элемтә җирләре статусы булмаган башка җир кишәрлекләрендә урнашкан элемтә корылмаларын торгызу буенча элемтә предприятиесе тарафыннан кичектергесез эшләр башкарылганда җир кишәрлеге милекчесе (биләүчесе, файдаланучысы, арендачы) белән элемтә предприятиесе зыянны тиешенчә түләү хакында килешә алмасалар, яисә милекче (биләүче, файдаланучы, арендачы) тиешле актны төзүдә катнашудан баш тартса, бу шартлар торгызу эшләрен башкару өчен тоткарлык була алмый һәм элемтә корылмасы милекчесен китерелгән зыянны түләүдән азат итми.

41 статья. Халыкара элемтә челтәреннән файдаланганда бәхәсләрне хәл итү

Татарстан Республикасының һәм чит дәүләтләрнең элемтә предприятиеләре арасында элемтә өлкәсендәге мәсьәләләр буенча бәхәсләр тиешле халыкара шартнамәләрдә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы шартнамәләрендә һәм килешүләрендә билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

## X бүлек. Халыкара хезмәттәшлек

42 статья. Халыкара хезмәттәшлек

Элемтә өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре һәм килешүләре нигезендә законнар белән гамәлгә ашырыла.

43 статья. Элемтә өлкәсендәге халыкара хезмәттәшлеккә карата кулланылучы хокук

Әгәр шартнамәләрдә башка дәүләт законнарын куллану күздә тотылмаган булса, элемтә өлкәсендәге халыкара проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы Татарстан Республикасының физик һәм юридик затлары чит ил оешмалары һәм гражданнары белән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә шартнамәләр төзиләр.

## XI бүлек. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе

44 статья. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе

Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына "Элемтә өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына өстәмә кертү хакында" Татарстан Республикасы законы проектын әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына кертүне йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 23 сентябре
N 1780